ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» 129-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Габделҗанов, М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» 129-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 497-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Габделҗанов,
М.Һ. Галиев,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның төп принциплары хакында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 304-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә гражданнар сәламәтлеген яклау, шулай ук шундый эчемлекләрне эчүдән зыян килүне кисәтү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр**

1. Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген, медицина эшчәнлеген, мәдәният, физик культура һәм спорт эшчәнлеген турыдан-туры гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, урыннарда тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату тыела.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны түбәндәге очракларда чикләргә хокуклы:

1) «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

оештырыла торган гавами чаралар вакытында гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм шундый урыннар янында чикләре Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелгән чаралар үткәрүне килештергәндә билгеләнә торган территорияләрдә;

2) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырыла торган физик культура чаралары һәм спорт чаралары, спорт ярышлары үткәрү вакытында.

4 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроле**

1. Федераль законның 2 – 3 статьялары һәм әлеге Закон белән билгеләнгән тыюларны һәм чикләүләрне үтәүгә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тонусны күтәрә торган (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен гамәлгә ашыруга вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте тарафыннан башкарыла.

2. Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы Федераль законның 2 – 3 статьялары һәм әлеге Закон белән билгеләнгән тыюларны һәм чикләүләрне оешмалар, индивидуаль эшкуарлар, юридик зат төземичә генә эшчәнлеген башкаручы крестьян (фермер) хуҗалыклары, Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан үтәүдән гыйбарәт.

3. Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясындагы «ж» пункты нигезендә сәламәтлек саклау мәсьәләләрен координацияләү, шул исәптән җәмгыятьнең сәламәт булуын саклау һәм ныгыту, сәламәт тормыш рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру, гражданнарда сәламәтлеккә җаваплы мөнәсәбәт культурасын булдыру Россия Федерациясе һәм субъектларның уртак карамагындагы мәсьәлә булып тора.

«Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның төп принциплары хакында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә РФ субъектлары законнары белән белем бирү эшчәнлеген, медицина эшчәнлеген, мәдәният, физик культура һәм спорт эшчәнлеген турыдан-туры гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, урыннарда тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләрне сату тыелырга мөмкин. Шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнары белән тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату вакытына һәм урынына чикләүләр дә кертелергә мөмкин.

Тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрнең башка эчемлекләр белән чагыштырганда үз үзенчәлекләре бар, чөнки алар составына тонусны күтәрә торган компонентлар: кофеин, таурин, L-карнитин, глюкуронолактон керә. Әлеге эчемлекләрнең төп компонентлары – синтетик кофеин, тонусны күтәрә торган рөхсәт ителгән дару үсемлекләреннән яки аларның экстрактларыннан ясалган табигый биологик актив матдәләр, шулай ук витаминнар (С, РР, В2, В5, В6, В12).

Энергетик эчемлекләрне җитештерүчеләр тәм бирүче өстәмәләр, җәлеп итүчән төргәкләр куллана, массакүләм маркетинг кампанияләре үткәрә, кофеинның, тауринның, витаминнарның уңай тәэсиренә һәм аларның чыдамлылыкка, эшкә сәләтлелеккә, физик үсешкә уңай йогынты ясавына басым ясыйлар, бу яшьләр һәм спортчылар өчен аеруча әһәмиятле.

Ләкин мондый эчемлекләрнең кешенең сәламәтлеге өчен куркыныч ягы шунда ки, кофеин, шикәр, витаминнар, аминокислоталар һәм үсемлек матдәләренең энергетика эчемлекләрендәге тупланышы гади продуктларга яки үсемлекләргә караганда югарырак. Аерым алганда, мондый эчемлекләрдә гадәттә кофеинның күләме тәүлеккә кулланырга рөхсәт ителә торган нормадан (тәүлегенә 150 дән алып 320 кадәр мг/л) югарырак. Тонусны күтәрә торган эчемлекне даими рәвештә көненә бердән артыкны эчү сәламәтлеккә зыян китерергә, беренче чиратта йөрәк-кан тамырлары системасын зарарларга, нерв һәм психик авыруларны көчәйтергә мөмкин.

Федераль закон тарафыннан бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр

турында» Татарстан Республикасы законы проекты белән түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

белем бирү эшчәнлеген, медицина эшчәнлеген, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне турыдан-туры гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, урыннарда тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны тыю;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырыла торган гавами чаралар вакытында һәм физик культура чаралары һәм спорт чаралары, спорт ярышлары үткәрү вакытында гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мондый эчемлекләр сатуны чикләү хокукы бирү.

Закон проекты тарафыннан тәкъдим ителә торган тыюлар һәм чикләүләр кертү тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрнең гражданнар сәламәтлегенә тискәре йогынты ясавы белән аңлатыла.

Югарыда бәян ителгән тыюларның һәм чикләүләрнең үз көченә керү датасын 2026 елның 1 сентябреннән билгеләргә тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.